**Абыем Хәмзә турында.**

Абыем Хәмзә 1945 нче елның 26 февралендә туа, гаиләбезнең дүртенче баласы (малае) була. Бөек Ватан сугышының соңгы еллары…, илебез сугыштан бик нык талчыган, хәерчелек, авыр тормыш еллары. Шуңадыр инде, Хәмзә абыебыз сәламәтлек ягыннан урысчалатып әйткәндә слабыерак булган. Хәтерлим әле әниемнең сөйләгәнен: бервакытны аның башы кычулаган (ул нинди авыру булганын хәзер әйтә алмыйм), чәчләре нык үскәч, әниемнең сеңлесе Хәлимә апа аның башын нык үскән чәчләрдән чистартырга булган; Хәлимә апа янышнан кайтып килгәндә урамдагы аны күргән кешеләр, алалы-тиләле башын күргәч, сорыйлар икән - Хәмзә, чәчеңне кем алды? - дигәч, ул - Хәлиматтәй кырыкты - дип җавап биргән. Үсә торгач, мәктәптә укыганда, ир-малайларны военкомат сәламәтлекләрен тикшергәндә абыйның үпкәсендә шик табалар. Әле мин дә хәтерлим, аңа пеницилин дип аталган укол ясарга кечкенә пыяла шешәләр тутырып җибәргәннәр иде, ләкин абыем ул уколларны алмады, ә мин алар белән уйный идем. Шуңа карамастан, абый бик тә җитез, хәрәкәтчән булды. Күп нәрсә белән кызыксына торган иде. Сигезенче-тугызынчы классларда укыган чагы булгандыр, радио белән бик кызыксынып китте; ул вакытта бу шөгыль радиохулиганлык дип атала иде. Билгеле, бу эш этигә белдермичә яшерен эшләнә торган һәм бу эшне без икәү генә белә идек, чөнки ул мине безнең өйдәге радио кырында калдыра иде, ә үзе күрше Магсум абыйларның радиосының үзе билгеләгән дулкынына (радиоволны) кереп: Я сова, как слышишь, я сова, раз, два, три, - дигән сүзләр әйтә, алардан чыккач, миннән кызыксына иде нәтиҗә белән.

Абыйларның кечкенә чакларында этиебез хромка гармошкасы алып кайткан, һәрбер абый гармунда уйнарга өйрәнгән, ә инде Хәмзә абый бик тә нык мавыккан бу шөгыль белән, шуңадыр инде, ул музыка буенча бик тә нык алга киткән абыйлар арасында. Мәктәптә укыганда ул өйгә мандолина дигән музыка коралы алып кайтып уйнап утыра торган иде. Минем уйлавымча, ул мандолинада бик осталарча уйный иде. Аннан соң, безнең иске өебездә укытучы Аликин Нурулла абый үзенең гаиләсе белән торган чагында, аларның Страдевари скрипкасы бар иде, Хәмзә абый шул скрипкада да уйнап карау бәхетенә ирешә. Тора-бара гитара музыка коралы аны кызыксындыра башлады, ә аны алырга акча табу максаты белән дә, болай да ул тик кенә тормавы белән, имән каерысы, гөлҗимеш-балан җыеп, кумак тотып - аның тиресен киптереп, агентка тапшырып акча җыеп, гитара сатып алды. Ул аның белән генә тукталып калмады. Искәндәр абыебыз Германиядән (армиядә служить итеп) кайтканда Хәмзә абыйга авыз гармуны (губная

гармошка) алып кайтты.Бу музыка коралы Хәмзә абый өчен бик тә нык яраткан нәрсә иде; ул  аның белән һәрвакытта, аерылмыйча, кесәсеннән төшермәде, шундый матур көйләр көйли иде ул. Шулай да бервакыт мин аннан сорадым - ә нигә син бер дә җырламыйсың?- дигәч, ул - минем музыкальный слух юк, - диде; мин аптырап калдым, аңламыйча: ничек инде, бөтен музыка коралларында уйныйсың, ә җырлый алмыйсың?

Чыгарылыш мәктәп еллары якынлашканда, Хәмзә абый бик тә нык самолёт, сугыш (военные сверхзвуковые) ракеталары белән кызыксына башлады, ул ясаган рәсемнәрдә гел шул оста ясалган ракеталар иде һәм аның бердән бер хыялы - лётчик булу иде. Мәктәпне тәмамлап, ул үзенең хыялын тормышка ашыру максаты белән Куйбышевтагы очучылар әзерли торган (Куйбышевское лётное)  училищега китте. Имтиханнарны уңышлы гына биргәч, очучыларны физик (сәламәтлек) яктан тикшеру вакытында  узмыйча, Куйбышевтан  кайтып, имтихан биргән документлары белән Алабуга педагогия институтының физико-математика бүлегенә укырга керде. Институтта укыган вакытларында да ул үзен кызыксындыра торган шөгыльләр белән  укудан буш вакытын уздырды.  Алабуга милиция мәктәбенә бокс белән шөгыльләнергә  йөрде, турнирларда катнаша иде. Мин аннан сорый идем: Син нинди категориядә катнашасың соң? - дигәч, ул: Наилегчайший вес минем, мин бит 48 килограмм, - диде. Авылда ял көннәрендә, кайткач шөгыльләнергә дип, капчыкка ком тутырып - боксёрская груша ясап, тополь агачына  элеп куйды; шуны боксёр перчаткаларын киеп (Алабугадан алып кайтып йөреп) төяр иде; ике пар перчатка алып кайтып миңа бер парын  кидерер иде дә, - миңа каршы тор, - дип суккалар иде; аның ударлары көчле булгач, миңа аңа каршы тору бер дә охшамый торган иде. Шул ук вакытта ул музыка кораллары белән шөгыльләнүне дәвам итте; тагы шул милиция мәктәбендә тынлы (духовой) оркестрда уйнарга йөри башлады. Ул вакытта аны музыка коралы - трубалар кызыксындырган булгандыр, ул - бердән,ә икенчедән - духовой оркестрда уйнау аңа өстәмә акча эшләү кәсебе дә иде, чөнки ул заманнарда духовой оркестрда уйнау демонстацияләрдә һәм урындагы кешеләрне (партия работниклары, райисполком кешеләре, атаклы кешеләрне) соңгы юлга озатканда кирәкле чара булып тора иде. Мин аннан сорый идем: Күпме акча бирәләр соң сиңа бер кешене күмгәндә уйнаган өчен, - дигәч, ул: Ун сум бирәләр, - диде. Ун сум ул чакта зур акча иде. Ял көннәренә авылга үзе белән шул духовой оркестр коралы - труба алып кайтып, ишек алдына чыгып уйнар иде. Саксафон дигән музыка коралы аны бик каты гына кызыксындыра иде. Әмма саксафонның бик кыйммәтле музыка коралы булуын ул яхшы аңлый иде.

Шулай да бер көнне ул саксафон алып кайтты авылга, шулай ук ишек алдына чыгып матур итеп уйнады. Мин тагы аннан сорый идем: Ә рояльдә уйный алыр идеңме, уйнаганың бармы? - дигәч, рояльдә уйнап караганын сөйләде. Нинди инструментта әле уйнаганың юк? - дип сорагач, ул: Органда уйнап карарга иде, - диде; ләкин андый органнарны ул киноларда гын күргән булгандыр инде, чөнки безнең якларда андый музыка коралы юк иде әле ул чакларда.

Институтны тәмамлаганнннан соң Хәмзә абыйны Кама Тамагы районына бер авылга укытучы итеп җибәрделәр. Ул анда физика, математика дәресләрен, лаборатория эшләрен алып барган. Озак та укытмады, аны армия сафларына алдылар. Ул Петрозаводскийда хезмәт итте. Анда да ул үзенә охшаган шөгыль - радиолокатырчы булган; бер ел хезмәт итеп авылга кайтты. Белемен яңарту максаты белән Киров политех.институтының Вятские Полянnetwork филиалына энергетика факультетына читтән торып укырга керде. Шул ук вакытта Бәзәкә авыл мәктәбендә физика, математика укытучысы булып эшләде. Ләкин укытучы булу аның күнеленә бик хуш килмәде. Ул елларда яңа эшкә кертелгән электр подстанциясенә элетромонтер булып эшкә керде. Эштән буш вакытларында бер дә тик тормады, нәрсә белән булса да мәшгуль булды. Күрше Рифат белән икесе электрогитара ясадылар. Клубка яңа гитара һәм ударный инструмент алгач, Хәмзә абый соло гитарада, Рифат ритм гитарада, ә ударный инструментта яшь егет Гайнуллин Рифкатьне утыртып, музыкаль ансамбль оештырдылар. Ул вакытлардагы танцыларны, ял итү кичәләрен искә төшерергә генә калды; күпме яшьләр җыела иде клубка, тирә-юнь авыллар белән чагыштырганда андый кичәләр тик безнең Бәзәкәдә генә булгандыр!

Электросетьтә эшләгәндә эш буенча дәрәҗәсен күтәрү максаты белән Хәмзә абыйны Нижнекамск шәһәренә күчерделәр (ул вакытта баш управление шунда иде). Ләкин шәһәрдә яшәү абыйга охшамый иде. Шуңа ул кире авылга кайтып колхозга энергетик булып урнашты һәм гаилә корып җибәрде. Ул аңлый иде - һәр гаиләнең үз йорты булырга тиеш. Шуңа ул йорт төзүне үзенең төп максаты итеп куеп йорт төзергә кереште. Аның табигате шундый иде - эшне башлагансың икән, аны азагына кадәр эшләп бетерергә! Бер эшне дә ярты юлда калдырмады, тырышты, тырмашты, кешедән ярдәм сорарга яратмады, ничек кенә булса да, алдына куйган максатын тормышка ашырырга омтылды. Шул авыр эшләрдәндер инде, сәламәтлеге дә какшап китте, җитмәсә үзенең ялгышлыгы белән электр тогына да эләгеп алды, ә ул бик тә йөрәккә кире йогынты ясый торган нәрсә; астма белән дә еш авырта башлады. Гаиләдә туган ике малай мәктәпне тәмамлаганнан соң этиләре

кебек энергетика буенча белем алырга Казан энергетика институтына укырга керделәр. Олы улы Альберт институтны кызыл дипломга тәмамлап кайтканнан соң Хәмзә абый, горурланып, улының кызыл дипломын тотып, аны эшкә урнаштыру максаты белән электросеть директоры янына керде. Аның шатлыгы йөзенә чыккан иде ул чакта. Малайлар әтиләре кебек хезмәт сөючән, булдыклы, белемле, тырыш балалар булып чыктылар.

Ләкин тормыш тигез генә бармый шул, юлларда киртәләр, каршылыклар чыгып тора…

(*Дәвамы бар…*)

*Гүзәл Габдуллина-Гыйльфанова, 2018 ел.*




*Уңнан беренче - Хәмзә абый.*



*Алабуга педагогия институтында укыган вакыт; институт тулай торагында;  Әмир(сулда) һәм Хәмзә абыйлар.*



*Дус иптәше Бакаев Владимир белән институтта укыган еллары.*

*Хәмзә абый уңда.*



*Кама Тамагы районындагы авыл мәктәбе хезмәткәрләре.*

*Хәмзә абый арттагы рәттә сулдан өченче.*